**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2019 Балык Бистәсе штп. № 174пи

“2019-2021 елларга Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү” муниципаль программасын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 7 июлендәге “Шәхси ярдәмче хуҗалык турында” 112-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге “Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы турында” 717 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 30 мартындагы ”Татарстан Республикасы халкының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү Концепциясен раслау турында” 136 номерлы карары нигезендә, авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә, шул исәптән Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә үзидарәлек ярдәмен күрсәтү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. “2019-2021 елларга Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү” муниципаль программасын расларга (теркәлә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 23 маендагы
174 пи номерлы карары белән
расланды

# “2019-2021 елларга Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү” муниципаль программасы

Балык Бистәсе штп., 2019

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | “2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү” муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| **Программаны эшләү өчен нигез** | Халыкның ШЯХ ларын хокукый җайга салу түбәндәге норматив актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:<br>-Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе;<br>- Россия Федерациясе Гражданнар кодексы;<br>-2003 елның 7 июлендәге “Шәхси ярдәмче хуҗалык турында” 112-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>-1992 елның 19 июнендәге “Россия Федерациясендә кулланучылар кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) турында” 3085-1 номерлы Федераль закон;<br>-1995 елның 8 декабрендәге “Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында” 193-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>-2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 209-ФЗ номерлы Федераль |

| | |
|---|---|
| | закон. |
| **Программаның заказ бирүче-яраштыручысы** | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Төп эшләүчеләр** | Балык Бистәсе муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе; Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаның максаты** | -Шәхси ярдәмче хуҗалыкларның (ШЯХ) тотрыклы эшләвен тәэмин итү һәм мөгезле эре терлекнең баш санын арттыру исәбенә аларның табышлылыгын күтәрү;<br>-базар икътисады һәм милек формаларының күптөрлелеге шартларында авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү;<br>-шәхси ярдәмче хуҗалык ияләренең (физик затларның) икътисади мәнфәгатьләрен яклау |
| **Программаның бурычлары:** | -Савым көтүенең продуктивлыгын күтәрү һәм баш санын арттыру нигезендә терлекчелек продукциясе күләмен арттыру;<br>-Тормышның матди дәрәҗәсен күтәрү;<br>-Авыл халкының хезмәт шартларын һәм мәшгульлеген яхшырту |
| **Программа чараларын төп башкаручылар** | Балык Бистәсе муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе; Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты; авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| **Программаны тормышка ашыру сроклары** | 2019-2021 еллар |
| **Финанслау чыганаклары** | Программаны Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетының өстәмә керемнәре хисабына финанслау күләме елга 1000 мең сум тәшкил итә.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлау характерына ия һәм Балык Бистәсе муниципаль |

| | |
|---|---|
| | районының бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиешле. |
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре** | Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисади нәтиҗәлелек гыйбарәт:<br>-шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерү эшчәнлеген үстерүдән;<br>-район авылларында яшәүчеләрнең нормаль көн күрүе өчен шартлар булдырудан;<br>-шәхси ярдәмче хуҗалыкларның (ШЯХ) тотрыклы эшләвен тәэмин итүдән;<br>-базар икътисады һәм милек формаларының күптөрлелеге шартларында авыл халкының тормыш-көнкүреш дәрәҗәсен күтәрүдән;<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыклар ияләренең (физик затларның) икътисади мәнфәгатьләрен яклаудан. |
| **Программа чараларына контроль системасы** | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты; Балык Бистәсе муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе; авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |

## 1. Проблемага тасвирнамә һәм аны Программа методлары белән хәл итүнең зарурлыгын нигезләү

Авыл хуҗалыгының тотрыклы үсеше төрле милек формалары хуҗалыкларының гармоник эшләвен ниятли. Агросәнәгать комплексында җитештерүне оештыруның сыгылмалы һәм көчле формаларының берсе булып төп бурычы гаиләә ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү торган халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыклары (алга таба – ШЯХ) санала. Халыкның ШЯХ лары авылда яшәүчеләр өчен туклану продуктлары керүнең төп чыганакларының берсе һәм Россиянең, шул исәптән Татарстан Республикасының да азык-төлек базарының актив субъекты була бара. Авыл хуҗалыгы милли икътисадның иң мөһим өлкәсе булып тора, ул агросәнәгать комплексында үзәк буынны төзи.

Республиканың аграр сәясәте кысаларында федераль һәм республика программалары тормышка ашырыла. Тагы да максатчанрак бюджет ярдәме методлары кулланыла башлады, бюджет средстволары хисабына процент ставкалары өлешенә акчалата ярдәм (субсидия) бирү нигезендә кредит бирү методлары камилләште, авыл хуҗалыгы җитештерүен һәм азык-төлек базарын дәүләт көйләве методларын файдалану киңәя төште.

Әмма күрелә торган чараларга карамастан районның шәхси хуҗалыкларында мөгезле эре терлекнең баш саны кимү тенденциясе бара, продуктивлыкның аерым күрсәткечләренең ирешелгән дәрәҗәсе җитәрлек түгел.

Әлеге мәсьәләне чаралар комплексын тормышка ашыру нигезендә хәл итү хуҗалык итүнең кече формаларын тотрыклы үстерү өчен шартлар булдыруны, терлекчелек продукциясе җитештерүне һәм малларның баш санын тизләтелгән рәвештә арттыруны тәэмин итәчәк.

Үзләренең төп функциясен – авыл хуҗалыгы продукциясе белән үз-үзен тәэмин итүне башкарып, халыкның ШЯХ лары районның азык-төлек базарын җитди генә тулыландыралар.

Халыкның ШЯХ лары торак пункттагы социаль мәсьәләләрне хәл итүгә шактый зур ярдәм итә һәм, барыннан да бигрәк, авыл кешесенең мәшгульлеген тәэмин итүгә, үзеннән арткан авыл хуҗалыгы продукциясен реализациялəп өстәмә керем алуга булышлык итә. Шулай итеп, халыкның ШЯХ лары, икътисадый институт буларак, авыл берләшмәсенең социаль тотрыклылыгының фундаменталь нигезен тәшкил итәргә тиешләр.

Халыкның күпчелек ШЯХ лары йорт яны кишәрлекләреннән алынган азыкны файдаланып, шулай ук арендага бирелгән җир пайлары (өлешләре) өчен түләү сыйфатында алынган авыл хуҗалыгы продукциясен файдаланып терлекчелек продукциясе җитештерүне алып баручы гаилә хуҗалыклары булып тора.

2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халыкның ШЯХ ларында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән авыл җирлекләре буенча 10296 йорт хуҗалыгы шөгыльләнә. Тулаем алганда Балык Бистәсе муниципаль районының халыкның 108 ШЯХ да 4 һәм аннан да артыграк баш савым сыер бар.

Ирешелгән нәтиҗәләрне ныгыту һәм ШЯХ ларда авыл хуҗалыгы продуктларын арттыру өчен бу юнәлештә бердәм якын килүне һәм гамәлләрне координацияләүне дәвам итү таләп ителә.

**2019 елның 1 гыйнварына авыл җирлекләре буенча йортлар саны һәм ШЯХ лардагы терлек саны турында мәгълүмат**

| Җирлекнең исеме | Йортлар саны | 4 һәм аннан да артыграк баш савым сыерлары булган ШЯХ саны |
|---|---|---|
| Анатыш | 273 | 4 |
| Б.Чүкәй | 240 | 8 |
| Биектау | 438 | 5 |
| Олы Елга | 335 | 7 |
| Олы Кульга | 271 | 3 |
| Олы Солтан | 174 | 4 |
| Бәтке | 265 | 7 |
| Олы Әшнәк | 197 | 4 |
| Зур Мәшләк | 287 | 1 |
| Казак Чаллысы | 221 | 5 |
| Корноухово | 232 | 3 |
| Күгәрчен | 385 | 7 |

| | | |
|---|---|---|
| Күки | 270 | 4 |
| К.Бөкәш | 694 | 4 |
| Масловка | 341 | |
| Түбән Тегермәнлек | 365 | 10 |
| Яңа Арыш | 224 | 5 |
| Полянка | 275 | |
| Рус Әшнәге | 247 | |
| Троикий Урай | 185 | |
| Уракчы | 196 | 5 |
| Шомарбаш | 201 | 1 |
| Югары Ырга | 165 | 6 |
| Шумбут | 181 | 2 |
| Шумково | 208 | |
| Балтач | 304 | 10 |
| Балык Бистәсе | 3122 | 1 |
| | | |
| Район буенча БАРЛЫГЫ | 10296 | 106 |

## 2.Муниципаль программаның максаты һәм бурычлары

Дәүләт булышлыгын исәпкә алып, халыкның ШЯХ ларының тотрыклы үсешен һәм нәтиҗәлелеген күтәрүне тәэмин итү;

Икътисадның әлеге секторына икътисади һәм социаль ярдәм күрсәтү.

Куелган максатларга түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән ирешергә мөмкин:

халыкның ШЯХ ларының нәтиҗәле эшчәнлегенә ярдәм итүче хокукый база һәм икътисади уңай шартлар булдыру;

халыкның ШЯХ ларын җир кишәрлекләре белән тәэмин итү;

азык базасын киңәйтү;

халыкның ШЯХ ларын финанс белән тәэмин итү механизмнарын булдыру;

авыл халкының социаль шартларын яхшырту һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрү;

авылдагы икътисади актив халыкның мәшгульлеген үстерү;

халыкның ШЯХ ларының хезмәттәшлегенең һәм кооперацияләштерүнең нәтиҗәле механизмын булдыру.

Әлеге Концепция кысаларында үткәрелүче төп чаралар юнәлдерелгән:

халыкның ШЯХ ларын үстерүне законнар һәм башка нормативлар белән тәэмин итүне камилләштерүгә;

халыкның ШЯХ ларының авыл хуҗалыгы оешмалары, крестьян-фермерлык хуҗалыклары, эшкәртү һәм сәүдә предприятиеләре белән хезмәттәшлеген камилләштерүгә һәм базар интеграциясенең бүтән формаларын оештыруда булышлык күрсәтүгә;

халыкның ШЯХ ларына финанс-кредит ярдәме күрсәтүгә;

халыкның ШЯХ ларына мәгълүмати-консультация хезмәте күрсәтүне оештыруга;

халыкның ШЯХ ларына ярдәм итүдә җирле үзидарәнең ролен күтәрүгә.

Хуҗалык итүнең кече формаларының авыл хуҗалыгы җитештерүенең көчле икътисади үсешен, авыл халкының мәшгульлеген тәэмин итүдә һәм аның тормыш дәрәҗәсен яхшыртудагы ролен күтәрү өчен алга таба авыл хуҗалыгында, шул исәптән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне һәм эшкәртүне оештыру өлкәсендә эшкуарлыкның кече формаларын үстерү күздә тотыла.

## 3. Программаны тормышка ашыру сроклары

Программа ел саен 2019 – 2021 еллар дәвамында тормышка ашырылачак. Районның һәм авыл җирлекләренең социаль-икътисади үсешенең ел йомгаклары буенча алынган нәтиҗәләрен исәпкә алып Программага ел саен төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

Программаны тормышка ашыру механизмы һәм тәртибе азык-төлек куркынычсызлыгы торышын яхшырту, район авыл халкының яшәү сыйфатын яхшырту, мал санын һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне арттыру өчен Программаның нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле авыл хуҗалыгы җитештерүе формалаштыруга юнәлтелгән чараларын башкаручыларның яраштырылган гамәлләре булып тора.

Финанс ярдәме алуга Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә көн итүче һәм гамәлдәге законнар нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы, авыл хуҗалыгы продукциясе һәм чималы җитештерү, эшкәртү һәм реализацияләү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы крестьян (фермерлык) хуҗалыгы башлыклары һәм әгъзалары, индивидуаль эшмәкәрләр булып торган гражданнардан гайре, гражданнар хокуклы.

.

## 4. ШЯХ оештыруның һәм эшләвенең хокукый нигезләре

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе,"Шәхси ярдәмче хуҗалык турында" Федераль закон, бүтән федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, шулай ук аларга ярашлы рәвештә кабул ителгән Балык Бистәсе муниципаль районы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Санап үтелгән хокукый актлар нигезендә ярдәмче хуҗалык шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яки) булдырылган җир кишәрлегендә шәхси хаҗәтләрне канәгатьләндерү максатларында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм эшкәртү буенча граждан һәм аның гаилә әгъзаларының эшмәкәрлеккә карамаган эшчәнлек формасы булып тора.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри пенсия иминияте буенча хокук мөнәсәбәтләренә керергә хаклы.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару бердәнбер табыш чыганагы булып торган хезмәткә яраклы яшьтәге гражданнар, шәхси ярдәмче хуҗалыкта җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен реализацияләүдән килгән керемне дә кертеп, гаиләнең җан башына туры килүче кереме Татарстан Республикасы буенча билгеләнгән яшәү минимумыннан артык булмаган шартта эшсез дип танылалар.

Гражданнар ирекле, иркен рәвештә үзләренең кирәк дип санаулары буенча шәхси ярдәмче хуҗалыкларында җитештергән авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү һәм кулланучы авыл хуҗалыгы кооперативлары аркылы һәм башка юридик затлар аша үзидарәлек һәм бүтән базарларда, эшкәртү һәм хәзерләү предприятиеләренә, оешмаларына реализацияли алалар.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның мөлкәте шушы максатларда бирелгән, алынган яисә булдырылган җир кишәрлегеннән, терлек, кош-кортлар, бал кортларыннан, күпьеллык утыртмалардан (куаклыклар, агачлар), торак биналар, хуҗалык һәм башка корылма һәм каралты-кураларыннан, авыл хуҗалыгы техникасыннан, җиһазлардан, инвентарьдан, транспорт чараларыннан һәм бүтән матди чыганаклардан, җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясеннән һәм аның эшкәртелгән продуктларыннан торырга мөмкин.

Халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыгы мөлкәтенең барлыкка килү (оешу) чыганаклары булып торырга мөмкин:

-шәхси ярдәмче хуҗалык иясе һәм аның гаилә әгъзаларының акча һәм матди средстволары;

- җитештергән продукциясен реализацияләгәннән килгән керемнәр;

-шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм авыл хуҗалыгы җитештерү һәм куллану кооперативларында, бүтән оешмаларда эшләүче гражданнар эшчәнлегеннән керемнәр;

-кыйммәтле кәгазьләрдән керемнәр;

-бюджеттан дотацияләр һәм дәүләт ярдәменең башка төрләре;

-банклар һәм бүтән финанс учреждениеләре кредитлары;

-гражданнарның һәм юридик затларның хәйриячелек һәм тиген взнослары, иганәләре, шул исәптән мирас тәртибендә, бүләк ителү яисә башка законлы нигездә алынган мөлкәт;

-натуралата түләү яки арендага алу тәртибендә авыл хуҗалыгы оешмаларыннан һәм шәхси эшмәкәрләрдән алынган терлек һәм бүтән матди средстволар;

-Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар.

## 5. Программаны реализацияләү механизмы

Программаны реализацияләү механизмы булып Программа чараларын башкаручыларның азык-төлек куркынычсызлыгы торышын яхшырту, район авыл халкының яшәү сыйфатын яхшырту, терлекнең баш санын һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне арттыру өчен нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле авыл хуҗалыгы җитештерүе булдыруга юнәлтелгән яраштырылган гамәлләре тора.

## 5.1. Гражданнарның индивидуаль саву аппаратлары алуга тотылган чыгымнарының 50% ын каплау

Программаны реализацияләү кысаларында ШЯХ га үзидарәлек ярдәме чараларын алга таба үстерү күздә тотыла.

Финанс ярдәме алу хокукына Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә көн итүче һәм гамәлдәге законнар нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы авыл хуҗалыгы продукциясе һәм чималы җитештерү, эшкәртү һәм реализацияләү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы һәм әгъзалары, индивидуаль эшмәкәрләр булып торучы гражданнардан гайре гражданнар ия.

ШЯХ алып баручы гражданнарга финанс ярдәме алу өчен 1 номерлы кушымтага ярашлы форма буенча гариза бирү зарур. Гариза ШЯХ алып барыла торган авыл җирлеге башлыгына ел саен 1 сентябрьгә кадәр бирелә.

Гариза нигезендә авыл җирлеге Башлыгы 2 номерлы кушымтага ярашлы формада финанс ярдәме өчен белешмә-исәп-хисап әзерли. Белешмә-исәп-хисап Балык Бистәсе Финанс-бюджет палатасына тапшырыла.

Матди ярдәмнең күләмнәре:

- индивидуаль саву аппараты алганда ШЯХ ка аппарат бәһасенең НДС һәм транспортировка чыгымнарыннан башка 50% ы кире кайтарыла (каплана).

Алу фактын раслаучы документ булып тора: сату-алу шартнамәсе, тулы бәяне түләү фактын раслаучы документлар.

Финанс ярдәме алган ШЯХ алып баручы гражданнар ШЯХ алып барыла торган авыл җирлегенә квартал саен сыерларының баш саны турында мәгълүмат тапшырырга тиеш.

Финанс ярдәме алуның зарури шарты булып 4 һәм аннан да күбрәк савым сыерның булуы һәм җирлекнең хуҗалык кенәгәсендә күрсәтелгән баш санының шуннан соңгы өч ел дәвамында саклануы тора.

Финанс елы дәвамында файдаланылмаган ассигнование лимитлары аннан соңгы финанс елында финансланмыйлар.

## 5.2. Программаны үтәү критерийлары

Программа чаралары шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерү эшчәнлеген үстерүгә һәм Балык Бистәсе районы авылда яшәүчеләренә нормаль көн күрү өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программаны үтәү критерие булып сөт җитештерүне арттыру һәм савым сыерлар санын 2018 ел дәрәҗәсендә саклап калу тора (тулаем авыл җирлеге буенча).

## 6. Контрольне оештыру

Бюджет средстволарын максатчан файдалануга һәм муниципаль программаны реализацияләүнең нәтиҗәлелегенә аудит контролен Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан бирелгән субсидияләр аларны максатчан билгеләнештә файдаланмау һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру фактлары ачыклану буенча кире кайтарылырга тиешләр.

Субсидияләрнең ирекле рәвештә кире кайтарылуын кире кагу очрагында бюджет средстволары гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә түләтелә.

Программа чараларын реализацияләүнең барышы һәм нәтиҗәләре ярты ел саен авыл җирлекләре башлыклары катнашында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында тикшерелә.

Программаны реализацияләү турында хисап квартал саен Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгына тапшырыла.

**Кушымта № 1**

**Индивидуаль саву аппаратлары алганда субсидия алуга гариза**

Мин,________________________________________________________________
(шәхси ярдәмче хуҗалык иясенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
____________________________________________________адресы буенча яшим.
(яшәү урынының адресы)
Мине индивидуаль саву аппаратлары алганда субсидия алу программасында катнашучылар составына кертүгезне үтенәм.
Катнашучы турында мәгълүматлар:
1.Паспорт мәгълүматлары:
серия________№________________________________________________
Кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән:___________________________________
ИНН(салым түләүченең таныклау номеры)_________________________________
2019 елның 1 гыйнварына савым сыерлар саны – __________баш.
Гаризаны тапшыру датасы “___”_______20___ел

Шәхси ярдәмче хуҗалык иясенең имзасы ____________________

**Кушымта№2**

201__елда индивидуаль саву аппараты алу белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга шәхси ярдәмче хуҗалыкларга Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирүгә үрнәк белешмә-исәп-хисап

| Авыл җирлеге исеме | Субсидияләр алучының (ШЯХ) Ф.И.А.и. | Алынган җиһазның бәясе (НДС тан башка, сумнарда) | Күчерүгә субсидияләр күләме (графа.3*50%) сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Тапшырылган документларның дөреслеген раслыйбыз:
___________авыл җирлеге Башлыгы________ _________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)